# «МӘҢГЕЛЕК МИЗГЕЛЛӘРЕ»
## Мансур Сафинга
## 75 яшь тулу уңае белән әдәби-музыкаль кичә
*(түбән сыйныф укучылары өчен)*

*Талгын гына көй агыла, сәхнәгә ике алып баручы чыга.*

**1 нче алып баручы:** Мин – Ватанчы! Табигатьче!
Милләтче генә түгел.
Каеннар кебек яратам
Туган ягымның күген.

Сандугачлардай ианам
Язның ал вәгъдәсенә!
Мәҗүсидер күңелләрем –
Назәги моңнар сеңә.

**2 нче алып баручы:** Җир-ананың җыр-баласы
Булып яшим галәмдә:
Шуңа күрә бар әйтәсем –
Кулымдагы каләмдә.

Мин – Ватанчы! Табигатьче!
Сулышларыбыз – бергә.
Канатым канап, егылсам –
Җирләгез җилле үргә:
Җирсүем булсын түрдә...

*«Мин – Ватанчы!»*

**2 нче алып баручы:** Хәерле көн, кадерле укучылар, хөрмәтле кунаклар. Без бүген шушы матур залга шигърият, шагыйрь бәйрәменә җыелдык.

Шагыйрь бәйрәме, Татарстан һәм Россия язучылар берлекләре әгъзасы, шагыйрь, прозаик һәм тәрҗемәче, журналист, укытучы, Шәйхи Маннур, Эдуард Касыймов, Егор Уткин, Риза Шәфи исемендәге әдәби премияләр иясе, «Хезмәт ветераны», «КАМАЗ төзелеше ударнигы» почетлы исемнәренә лаек булган һәм унлап медаль белән бүләкләнгән Мансур Сафинның 75 яшьлек юбилей бәйрәме.

**1 нче алып баручы:** Мансур Габдулла улы Сафин 1949 елның 11 маенда Кемерово өлкәсенең Анжеро-Судженск шәһәрендә шахтер гаиләсендә туа. Балачак һәм мәктәп еллары Татарстан Республикасының Мамадыш шәһәрендә уза. Ул монда беренче адымын ясаган, тәүге авазлардан әти-әнисенә беренче сүзләрен әйткән, хәрефләрдән беренче җөмләләрен төзегән, беренче шигырьләрен язып, дөньяга чыгарган.

**2 нче алып баручы:** Булачак шагыйрьнең әти-әнисе Габдулла абый һәм Әминә апа – катлаулы биографияле кешеләр. Алар тырыш игенче һәм абруйлы мулла гаиләләреннән. «Халык дошманнары» дигән мөһер сугылганлыктан, үзләренә югары белем алу мөмкинчелеге булмый, әмма алар дүрт балаларына да югары, университет белеме алырга ярдәм иткәннәр.

**1 нче алып баручы:** Мансур Сафин – Мамадыш шәһәренең икенче политехник урта мәктәбендә белем ала. Бу мәктәп ул вакытларда Казан дәүләт педагогия институтының база мәктәбе була. Мансур беренче шигырьләрен мәктәп елларында, ун яшендә яза башлый. Ул елларда аңа мәктәп газетасы мөхәррире дә, пионер җыелышларында, әдәби кичәләрдә үзе язган шигырьләр белән чыгышлар ясарга да туры килә.

**2 нче алып баручы:** Мансур Сафин бүгенге көндә балалар өчен нәшер ителгән унлап китап авторы. Шулардан «Сыерчык бураннары», «Сербакчага сәяхәт», «Ручеек» җыентыклары милли китапханә уздыра торган «Ел китабы» бәйгесендә дипломнарга лаек булалар. Автор 2000 елда, балалар әдәбияты өлкәсендәге уңышлары өчен, Шәйхи Маннур исемендәге Татарстан Язучылар берлегенең әдәби премиясе белән бүләкләнә.

*Укучылар чыгышы.*

**1 нче укучы:**

Сокланмый булдыра алмыйм,
Җырларын тыңлап туйгач:
Шундый тылсымлы кубызны
Ничек ясый сандугач?

«Миңа да серен әйтмәсме?»
Диеп тыңлаган булам.
Аның асыл җырларыннан
Үзем моң булып тулам!

«*Сандугач*»

**2 нче укучы:**

Курчагымны уятырмын,
Утыртырмын каршыма.
Ул да: «Укыйсым килә! – дип,
Мин тырыш!» – дисен миңа.

Мин аңа җырлар җырлатып,
Шигырьләр сөйләтермен,
Үзем кебек шәп укучы
Булырга өйрәтермен.

*«Монолог»*

**1 нче алып баручы:** Мансур Габдулла улы күп төрле талант иясе, шигърият, проза, әдәби тәнкыйть, тәрҗемәләр белән шөгыльләнә. Шулай ук өч пьеса авторы. Авторның, режиссер Ринат Аюпов тарафыннан куелган «32 март» пьесасы Казан шәһәренең яшь тамашачы татар театрында күп еллар куелып килә. Аның шигырьләренә композиторлар (Людмила Ткачук, Рубис Зарипов, Рәхим Гайсин, Валерий Манкушев һ.б.) игътибар итәләр. Күп кенә шигырьләре көйгә салына.

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

Хыялларымнан тартынмыйм,
Алар бихисап түгел.
Җанкисәгең, бердәнберең,
Буласым килә бүген.

Минсез яши алмый торган,
Назлы кояшлы күгең.
Серле һава-офыкларга
Туласы килә бүген!

Күңелең сазына моңланып,
Мәхәббәт белдерүең.
Миңа гына дигән мәлдә
Тыңлыйсы килә бүген.

Бәхетләргә өметләнәм,
Күңелдә юк бар шигем...
Сине җаным-тәнем белән
Кочасы килә бүген!

*«Сагыну җыры»*
*(Мансур Сафин сүз., Рубис Зарипов көе)*

**1 нче алып баручы:** Комазан – Берсут урманнары, Нократ – Чулман болыннары аны яшьтән үк шигырьләр язарга илһамландырган. Ул унынчы сыйныфны тәмамлагач, Оренбург зенитно–артиллерия училищесында хәрби белем алып, Совет Армиясы сафында хезмәт итә, 1970 елны Мамадышта педогогия училищесын, аннан соң Казан дәүләт университетының физика факультетын тәмамлый.

**2 нче алып баручы:** Чаллы шәһәренә Мансур Сафин 1978 елның көзендә килә. Ул, беренче көннәрдән үк, шәһәр әдәби оешмаларының актив әгъзасына әйләнә. «Орфей» һәм «Ләйсән» әдәби оешмаларына йөри. Шигырьләрен рус

һәм татар телендә ирекле яза. Нәкъ шушы елларда Мансур Сафинның КАМАЗ турында шигырьләре шәһәр, район, республика газета-журналлары битләрендә дөнья күрә. 1980 елларда инде «Новый мир», «Литературная Россия», «Советская культура», Учительская газета» кебек җитдирәк журналларда басыла башлый. Шулай ук Мәскәүдә нәшер ителүче шигъри җыентыкларда да урын ала («Середина земли родной», «Лебеди над Челнами»). Соңрак авторның «Хәерле иртә», «Надежда, Вера, Любовь» исемле шигырь китаплары да дөнья күрәләр. Бүгенге көндә ул биш дистәдән артык китап авторы. Мансур Сафинның шигырьләре үзләренең эчкерсезлеге, гадилеге белән күңелгә үтәләр.

*Укучылар чыгышы.*

**3 нче укучы:**

Тәүге яшен яшьнәгәндә
Дәртләнеп китә күңел:
Уйлар һаман яшьлегемдә,
Һич картаюда түгел!

Тамчы-тамчы булып еллар
Уза да китә икән –
Гомерләр,
Яшеннәр кебек
Яктырып сүнә икән...

И, нарасый яңгыр ява
Тәүге тиере су булып.
Яшен яшьни, яшен – дәва:
Сөендерә бит, көлеп!

«*Тәүге яшен*»

**4 нче укучы:**

Пешкән чия – офыклары,
Зөбәрҗәт – инешләре!
И туган як – хәзинәнең
Безгә дә тиешләре!

Җыр аһәңе – күңелләрдә,
Тургайлар – шигырьләрдә,
Туган якның кайтавазы –
Яшеннәр дөбердәүдә.

Их, мәңгегә онытылмас
Балачак урамнары –
Изге хатирәләр булып,

Ажаган уйнаулары!..

*«Балачак аҗаганы»*

**1 нче алып баручы:** Мансур Сафин тәрҗемә эше белән университетта укыган елларда шөгыльләнә башлый. Саҗидә Сөләйманова һәм Гамил Афзалның әсәрләрен тәрҗемә итә. Соңрак Равил Фәйзуллин, Әхмәт Гадел, Шаһинур Мостафин шигырьләрен тәрҗемә итәргә алына. Көндәлек матбугат битләрендә аның тәрҗемәсендә Кол Шәриф, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Габделҗәббар Кандалый, Зыя Ярмәки, Нур Баян, Гамил Афзал, Нәҗип Мадьяров, Газиз Кашапов, һәм башка каләм ияләре иҗатыннан күп кенә тезмә һәм чәчмә әсәрләр дөнья күрә. Ә әдипләребез Эдуард Касыймов, Мәгъсум Насыйбуллин, Заһирә Гомәрова, Рәшит Бәшәрләрнең Мансур Сафин тәрҗемәсендә аерым китаплары басылып чыга.

**2 нче алып баручы:** Мансур Габдулла улы бүгенге көндә дә Чаллыдагы яшь талантлы каләм ияләре (Равил Мостафин, Нурислам Гафиятов, Рәкит Аллабирде, Рәзинә Сәетгәрәева һ.б.) әсәрләрен татарчадан русчага тәрҗемә итеп, укучыларга тәкъдим итү эшен дәвам итә.

**1 нче алып баручы:** Татар теленең үз моңы бар, рус теле дә үзенчәлекле яңгырашка ия. Мәдәниятләре бай, тамырлары тирән аларның. Шушы үзенчәлекләрне искә алып тәрҗемә итүне Мансур Сафин изге эш дип саный.

Рус шагыйрьләрен татарлар да белергә тиеш дигән максат белән, ул күренекле Михаил Лермонтов, Федор Тютчев, Марина Цветаева, Николай Рубцов, Владимир Высоцкий һ.б. тулы бер җыентыклар итеп бастырып чыгарды. Шушы урында рус шагыйрьләренең шигырьләрен татарча ишеттереп үтәсе килә.

*Укучылар чыгышы.*

**5 нче укучы:**

Кайчан гына, уйнап-җырлап туйгач,
Кайда өзелер гомерем – кем белә?
Тик бернәрсә аермачык бугай:
Ашыктырмас Алла Тәгалә!

Почетларның алтын чылбырына
Утыртылдым...Тел-тешем үтми...
Әй, кем шакый имән капкаларны
Сөяк бармак белән? Сак этне.

Өркеттереп. Җавап юк шул. Әмма
Койма өсләрендә чалгы – ай.
Ялтырыйдыр, үткен йөзен янә
Миңа таба төбәп, тоеп җай...

Көмеш муенчагымны өзәрмен дә,
Алтын чылбырымнан арынып,
Качармын чал ирек үзәненә,
Күкрәү күкрәгенә сарылып!..

«*Кайчан гына, уйнап - җырлап туйгач*»
*(Владимир Высоцкий «Когда я отпою и отыграю...»)*

**6 нчы укучы:**

Бүген мин күктән кунактыр
Синең тәүге илеңдә.
Кыр йоклый,
Урман йокламый
Изге туган җирендә.

Әнә бер ат дагалары
Үләнне ярып үтте.
Арган сыер тын абзарда,
Мөгрәп йокыга китте.

Сөйлим әле сиңа кайгы
Вә наз тулы хикәят;
Уяу сакчы – каз турында,
Йоклаганда бер хәят...

Кулларым эт йонын сыпыра –
Анда инде чал төшкән.
Алты сәгать тулар алды –
Таң атарга керешкән!

*«Бүген мин күктән кунактыр»*
*(Марина Цветаева «Нынче я гость небесный»)*

**2 нче алып баручы:** Шагыйрь – бөек халкының аерылгысыз бер баласы. Тамыры нык, шигърияте көчле. Мансур Сафин туган яктан көч алып иҗат итә, нәселенең изге чылбырын өзми яши бирә.

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

И, Мамадыш таңнары!
Әйди Нократ ярлары –
Тәүге бала чакларыма
Кайтасы иде бары...

И, туган як таңнары!

Бөдрә-бөдрә таллары.
Балачакның бәхет серен
Ачасы иде бары.

Әй, хатирә таңнары!
Урманнары сап-сары:
Кайдан төшкән бу фаҗига? –
Гомер үтә нибары...

*«Мамадыш таңнары»*
*(М.Сафин сүз.,З.Мөхәммәтдинов көе)*

**1 нче алып баручы:** Мансур Сафин туган ягының табигате белән тыгыз бәйләнештә. Бәллүр чишмә аны «дисбе тартып» көтә!

Беләм – сагыныплар ята:
Челтер – челтер дога укый,
Бәллүр дисбесен тарта.

«Бәллүр чишмә» шигырендә автор чишмә образын гәүдәләндерә, аны җанлы итеп күрсәтә: «Былбыллар белән ярыша, гөлләр белән серләшә», – ди.

**2 нче алып баручы:** Мансур Сафин шигырьләре гади дә, халыкчан да, тирән мәгънәви дә. Дөнья серләрен ачар өчен һаман да эзләнә шагыйрь. Йөрәк күзен ачып карый ул дөньяга!..

**1 нче алып баручы:** Кичә ахырында «Мамадышлы дусларыма» шигырен ишеттереп үтәсе килә. Дусларына язган сүзләре күңел кылларын чиртеп ала.

Юк шул, мәңгегә килмәдем,
Җыр мәңгелек булса да:
Күңелем сезнең белән калыр,
Йөрәккәем сулса да...

**2 нче алып баручы:** Нократтагы чал ташлардан
Миңа ядкарь куегыз,
Мамадышны сагыну хисен
Таң түренә уегыз.

Сезгә булган мәхәббәтне
Серләремне тоегыз:
Мин булырмын
Сезнең мәңге
Тере сулы коегыз!..

**1 нче алып баручы:** Аны дуслары беркайчан да онытмаслар һәм шагыйрьнең үтенечен үтәрләр. Киләчәк буын аның иҗат чишмәсеннән илһам алып яшәр. Ул моңа ышанып: «Мин булырмын сезнең мәңге тере сулы коегыз», – ди.

**2 нче алып баручы:** Кадерле дуслар, кичәбез ахырына якынлашты. Без кичәбезне Татарстан һәм Россия Язучылар берлекләре әгъзасы, Шәйхи Маннур, Эдуард Касыймов, Егор Уткин, Риза Шәфи исемендәге премияләр лауреаты Мансур Габдулла улы Сафин иҗатына багышладык. Үзенең бәрәкәтле иҗаты белән халкына хезмәттә булган әдипкә киләчәктә дә мул уңышлар тугрылык юлдаш булсын иде.

## Файдаланылган әдәбият

Зарипов, Р. Җырлап ачыла күңел: җырлар /ноталары белән / Р. Зарипов. – Яр Чаллы, ООО «Диамант», 2016. – 91 б.

«Мгновения Вечности» – «Мәңгелек Мизгелләре»: материалы Республиканской научно-практической конференции, посвященный творческой деятельности писателя Мансура Сафина / Составитель – Р.Г. Хамидуллина. – Казань: Редакционно-издательский центр «Школа», 2015. – 364 с.

Сафин, М. Хәерле иртә: шигырьләр, хикәя, әкиятләр / М. Сафин. – Чаллы, «КАМАЗ» нәшрияты, 1994. – 64 б.

Сафин, М. Сыерчык бураны: шигырьләр, табышмаклар / М.Сафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 48 б.

Сафин, М. Владимир Высоцкий: Ярсулы йөрәк / Мансур Сафин тәрҗемәләре / М. Сафин. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2008. – 60 б.

Цветаева, М. Канатлы күңел: Сайланма шигырьләр / Мансур Сафин тәрҗемәләре. Лилит Козлова кереш сүзе / М. Цветаева. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2008. – 44 б.